

Мослимә Якуп кызы Кильдеевага 90 яшь тулды. Ул гомерен туган Большая Поляна авылында vткәрә.
Мослимә Якуп кызы, олы яшенә карамастан, тошенкелеккә бирелә торган кеше тvгел; шат кvнелле ул, киләчәккә оптимизм белән карый. Бvген кvп кенә аналар ялгызлыктан интегә, әмма Мослимә апа тvгел – ул ялгыз тvгел; ярдәмчел кызлары һәрвакыт анын янында.
- Гомеремнен шулай vткәненә бер дә vкенмин, - ди Мослимә апа. – Тормыш итv - кырны атлап кvчv тvгел, диләр халкыбыз. Һәрвакыт янымда яхшы кешеләр булды. Шуна да авыр еллардагы кvргәннәремне, ярдәмчел кешеләр белән бергә булганга, чыдатып булды. Бер гаилә тосле яшәгән авылдашларым белән бар авырлыкларны жиндек. Бvгенге нинди матур коннәргә кадәр життем. Шундый олы юбилейны кvрермен дип тә уйламаган идем, ә кvрергә насыйп булды. Шулай шул, тормышта бер дә тошенкелеккә бирелергә кирәкми; яшәеш кvпне ала һәм кvпне бирә дә. Биргәнгә риза булып барырга кирәк.
Мослимә Якуп кызынын тормыш юлына кvз салыйк. Ул туган авылы колхозына 14 яшьлек яшvсмер буларак эшкә бара. Боек Ватан сугышы башлангач, тылда хезмәтнен ин авыры яшьләр һәм картлар кулына кала. Әтисе Якуп абый сугышка киткәч, Уторовлар гаиләсендә биш балалы Анага донья итәргә туры килә. Шундый шартларда аларны туендырырга, ос-башларын карарга да кирәк бит. Әле житмәсә, олы улларын да фронка алалар. Әнисенен бер таянычы – Мослимә Якуповна гына кала. Ул әнисенә һәм кечкенә сенелләре, энеләренә дә таяныч була шул елларда. Сугышны беркемгә дә кvрергә язмаган булсын. Авырлыклар белән булса да боек Жинv, сугыштан сонгы якты тормыш тозvләр әле тарихта калды...
Кырык елдан артык Мослимә Якуп кызы Кильдеева туган Большие Поляны авылы колхозында мал-туар асрый. Кем бу эш белән таныш, ул мал-туар vстерvнен авырлыгын белә. Мослимә апанын тырышлыгы, яшьлеге аркасында барысына да олгерә: эшендә - хөрмәттә, ойләре, йорт-жирләрендә, бакчаларында да тәртип. Мослимә Якуп кызы Уторованы авылдашы Мобин Исмаил улы Кильдеев кvзләп йоргән, ошаткан. Ничек инде шундый унганнарны яратмассын; озакламый алар гаилә корып яши башлыйлар.  Матур, эшкә унган әниләренә тин кызлары да vсә Мослимә апанын. Әти-әниләре белемле дә итә аларны, кулларында профессияләре бар:  Розасы – шәфкать туташы-медсестра, Сарасы – авыл хужалыгында хезмәттә, Риммасы – балалар бакчасында тәрбияче. Бvген vз тормышлары белән яши алар.
Гаилә башы Мобин Исмаил улы да гомере буе туган авылы колхозында тырышып хезмәт

итә. Авылнын ГЭСында беренче электрик булып хезмәт биографиясен башлап жибәрә, аннары пилорамда, тегермәндә эшли. Район һәм авыл халкы тагы аны оста балыкчы дип искә алалар. Исса елгасы шул вакытлар балыкнын торлесенә бай иде. Мобин абый, буш вакытларын, балыкка йоргән; артып киткәнен саткан да. Мослимә апа аерым горурлык белән тормыш иптәше Мобине белән алтмыш ел бергә гомер итvе турында сойли. Чынлап та зур дата! Мобин абыйнын бакыйлыкка кvчкәненә сигез ел инде. Әмма ялгызлык авырлыгын кvрми Мослимә апа; кызлары - кvз нурлары, һәрвакыт янәшәсендә. Бу vзе зур бәхет.
Юбилеена килгән кунакларга, Россия Президенты В.В. Путинга Мослимә Якуп кызы Кильдеева изге теләкләре очен рәхмәтле. Һәм ул, ихлас кvнелдән, барыбызга аяз кvк йозе, тормыш юлыбызда яхшы кешеләр генә очрасын, дигән теләкләр тели.

**Н.Хәлил**